БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №22 (7039) | 20 февраль, 1990 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.

## Планнарны үтәп киләләр

«Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе коллективы еллык планнарны үтәүдә зур тырышлык һәм энергия куеп эшли.

Январь аенда Е. Т. Сидоров, В. А. Николаев, М. Н. Шәрәфетдинов җитәкчелегендәге бригадалар җир асты скважиналарына ремонт үткәрү буенча айлык планнарны уңышлы үтәделәр.

Идарә коллективы февраль ае планнарын да үтәячәгенә шикләнми.

## Авыл уңганнары

Нинди йомшак, ягымлы сүз. Әмма җирдә туып үскән, бөтен гомерен шунда эшләүгә биргән кешеләр җилкәсенә нинди авыр йөк төшүен һәркем дә белмидер әле. Ә З. Е. Онгина һәм О. А. Федушкина нәкъ менә шушындый җир хуҗалары да инде. Аларның беренчесе 30 ел гомерен сыерлар савуга биргән, икенчесе сарык фермасында эшли. Зинаида Егоровна хезмәтнең төрле формаларын үз җилкәсендә татыган кешеләрнең берсе. Менә шушы хезмәтләр арасында иң ошаганы, иң кулланышка яхшы дип табылганы аренда системасы булуына нык ышанды ул. Аның сүзләренә караганда, аренда звеносында эшләүчеләргә җаваплылыкны күбрәк үз өсләренә алырга туры килә. Хәзер янәшәдә эшләүчеләр алар хезмәтенең соңгы нәтиҗәләренә соклanып карыйлар, әмма көнләшеп түгел. Аларның звеносына тәҗрибәле савучы Галина Аркадьевна Изотова җитәкчелек итә, ул яшьләрне өйрәтә һәм үзе барысына да үрнәк булып тора.



Узган ел звено һәр сыердан 3325 килограмм сөт сауды. Хәер, быелгы январь коллективны бик сөендермәде — һәр сыердан 223 килограмм гына сөт савылды. Әмма февральдә эшләр җайланып китте. Чөнки хәзер звенода Н. И. Хурина, Р. Я. Белова кебек тәҗрибәле савучылар эшли.

О. А. Федушкина да фермада озак еллар буе эшли инде. Ул һәм З. Е. Онгина «Правда» колхозы хатын-кызлар советы вәкилләре буларак хатын-кызларның район конференциясендә катнаштылар. Фотохәбәрчебез Л. Шәмсуаров аларны нәкъ менә шунда фотога төшереп алган булган.

КПСС Үзәк Комитеты платформасы: фикерләр һәм тәкъдимнәр

## Карарларның үтәлешенә контроль көчәйсен

Пленумда миңа Мәскәү өлкә комитетының беренче секретаре В. Месяц чыгышы ошады, чөнки ул бүгенге авыл проблемалары белән бәйле мәсьәләләрне күтәрде. Бу уңайдан шуны да билгеләсем килә. КПСС Үзәк Комитетының үткән елгы март Пленумы карарлары чынбарлыкка бик акрын ашырыла әле. Күп очракта сөйлибез, ә конкрет эшләргә һаман кул җитми.

Бүгенге авыл турында сөйләгәндә җиргә кем хуҗа булырга тиешлеге мәсьәләсен хәл итми торып алга бару мөмкин түгел. Җир турында Закон проекты игълан ителде. Әмма аны урыннарда оешкан рәвештә тикшерү алып барылмый, сүз югары рангта гына кузгатыла. Аны, минемчә, партия оешмаларының барлык рангларында, беренче чиратта башлангыч оешмаларда тикшерү, авыл коммунистларының фикерләрен һәм конкрет тәкъдимнәрен белү кирәк. Законны кабул иткәнче аларның фикерләрен, теләкләрен, тәкъдимнәрен өйрәнү мөһим. Чөнки җиргә, төптән исәпләп карасак, алар хуҗа бит.

Литва коммунистларының XX съезды карарлары белән килешү мөмкин түгел. Бу, дөресен әйткәндә, партияне таркатуга юнәлдерелгән курс. Кире үрнәк бик тиз таралучан була бит.

**А. СУХОВ,**
Синдряков исемендәге колхозның партия комитеты секретаре.

Бер колхоз хәбәрләре

## Үзеңне табарга

«Восход» колхозы терлекчесе П. Л. Ванин яхшы үзешчән гармунчы. Өлкән яшьтә булуына да карамастан, фермадан кайткач, бигрәк тә кичләрен үзенең онытылмас гармуны төймәләренең тигез рәтләре буйлап бармаклары белән чабып үтә.

Петр Леонтьевич турында сөйләгәндә аның өстенлекләре хакында әйтми булмый. Ул бит җәен тракторчылар арасында беренче. Кәрусыз, намуслы. Җырлаган кебек эшли. Аңа карыйсың да шатланасың. Ә кышкы чорда — фермада терлек караучы һәм тагын алдынгыларның алдынгысы. Январь аенда 40 баш мөгезле эре терлек карап малларның тәүлек саен уртача 857 грамм артым бирүенә ирешә.

Хәтердә, элегрәк елларда һәрвакыт гармунчы авылда беренче егет булды. Аңардан башка кичәләр-кичә, туйлар-туй булмый иде. Күрәсең, бу лидерлык яшьтән П. Л. Ванинның аңына кергән. Ул икенче рольдә була алмый, бары тик алда, бары тик алдынгылар арасында, шуңа да кулын төшерми эшли һәм хезмәт аңа шатлык кына.

x x x

Нина Ильинична Петрова П. Л. Ванинның яшьтәше. Яшь чакларында бер вакытта кичәләргә бардылар, ә хәзер бергә эшлиләр. Аның карамагында да үстерү группасындагы 48 баш мөгезле эре терлек. Артым алу буенча да лидердан бик азга калыша. Аның группасында бу күрсәткеч 839 грамм тәшкил итә. Тәҗрибәле терлекчеләр узара ярышалар. Инде яшьләр дә үсеп җиткәннәр, ныгыганнар. Валерий Иванов, мәсәлән, 800 әр грамм үсеш алган, ә бит ул, әйтергә кирәк күптән түгел генә эшли фермада. Күрәсең, аңа үз урынын табу өчен күп вакыт кирәкмәгән.

Терлекчеләрнең намуслы хезмәт куюлары шатландыра. Намуслы хезмәт һәрчак уңышлы тәмамлана бит.

**А. АЛЕКСЕЕВ,**
баш экономист.

## Сөт ташучы Марат

Марат Ситдыйков туып үскән авылында төпләнеп калып шофер булып эшли башлады. Аңа колхоз идарәсе җаваплы хезмәтне — сөт ташу машинасын йөртүне тапшырды. Шуннан бирле елның теләсә кайсы фасылында Фома—Норлат маршрутында очратырга мөмкин аны. Ул хуҗалык терлекчеләре савып алган сөтне үзвакытында сөт-май заводына китереп җиткерү өчен зур тырышлык куя.

— Баштагы вакытта, юл булмау сәбәпле, зур кыенлыклар кичерергә туры килде,—дип искә ала ул чакларны Марат Нургатович.—1986 елга кадәр юлсызлык үзәккә үтте. Хәзер менә юл булгач, көнгә ике-өч рейс йөк китерү дә сиздерми. Продукциянең әрәм-шәрәм ителүенә дә юл куелмый.

Узган ел уңган автомашина йөртүченең тырышлыгы нәтиҗәсендә җитештерелгән продукциянең 85 проценты 1 сорт белән сатылды. Бу 1988 елдагыдан 18 процентка артыграк. Сөтнең майлылыгы да 0,02 процентка артты.

Тырыш шофер быелгы елны да нәтиҗәле тәмамлау өчен зур тырышлык куя.

**Г. КӘБИРОВ,**
«Игенче» колхозы.

## Ярдәм көтәбез

15 февральдән 16 сына каршы төндә билгесез автомобиль нефтьчеләрнең спорт комплексына каршы светофор баганасын бәрдереп аудара. Светофор сафтан чыга. Район эчке эшләр бүлегенең дәүләт автомобиль инпекциясе бу аварияда сәбәпчене ачыклауда ярдәм итүне сорап халыкка мөрәҗәгать итә. Бу машинаның маркасын һәм номерын күреп калучы кешеләр булса, милициягә хәбәр итүләре сорала.

**Район эчке эшләр бүлегенең дәүләт автомобиль инспекциясе.**

## Ел уңышлы башланды

**Муса Җәлил исемендәге колхоз сыер савучылары соңгы вакытта көнлек күрсәткечләрне 14 әр килограммга кадәр җиткерә башладылар. Бу узган елның шул көненә һәр сыердан 2,3 килограммга артыграк.**

— Сыерларга фураж пешереп ашата башладык, аннары быел азык та башка елдагыларга караганда яхшырак,—дип аңлата уңышның серен ферма мөдире Минхатыйп Алиев.— Савучыларның да хезмәте җиңеләйде, группаларда 18—20 шәр генә сыер калдырдык. Бу һәр сыерның яхшы ашатылуына, сөтнең савып бетерелүенә зур мөмкинлек тудырды.

Тәҗрибәле мөдир терлекчелектә эшнең болай оештырылуының отышлы булуын саннарда бик тиз аңлатып бирде. Хәер, алар күз алдында, һәркемне сөендерерлек. Савучылар үзләре дә аның өстенлекләрен тиз тойганнар. Ә аларга килгәндә исә, тырышлыкларына да, тәҗрибәләренә дә сокланырлык. Комплекста төп эшне күп еллар буе бер үк хатын-кызлар алып баралар. Аларның һәркайсы тырыш колхозчы гына түгел, күп балалы аналар да.

Январь ае нәтиҗәләре буенча Зәйнелгарәп Гыйләҗева беренче урынга чыкты. Ул үзенең группасындагы һәр малдан 405 килограмм сөт савып алды. Бүгенге көндә һәр сыердан 13 килограмм сөт сава. Икенче урында Тәслимә Рәхимова, аның күрсәткече 371 килограмм. Өченче урында — савучылар арасында бердәнбер егет Илшат Хәсәнҗанов, ул 348 килограмм продукция алды. Хәер, савучыларның башкалары да сер бирмиләр. Хәзерге вакытта көнлек күрсәткечләре белән Гамбәр Ахунҗанова, Фәүзия Мөхетдинова алда баралар. Беренчесенең уртача көнлек савымы 14 килограмм, ә икенчесенең — 13 килограмм.

Комплекста күбрәк сөт савып алу өчен һәркем зур тырышлык куя. Алар арасында Исламия Гыйльметдинова, Сания Ганиева, Исламия Камалетдинова, Миннегөл Сафиуллина да бар. Тудыру бүлегендә эшләүчеләр Халисә Зәйнетдинова, әнилекызлы Фәнүзә Садыйкова һәм Роза Гатина сыерларны чиста, сөтне мул бирерлек хәлдә тапшыру турында кайгырталар. Мәгълүм ки, сөт алу уңышында азык ташучыларның да өлеше зур. Алар — Минехан Хәсәнҗанов, Рәшит Гомәров, Сәхип Сәгыйров, Мансур Якупов, Әхтәм Рәхмәтуллин. Бу егетләр азыкны һәрчак вакытында китерергә тырышалар.

Әлбәттә, сөт алуның алдагы уңышы да комплекста эшләүче һәркемнең тырышлыгыннан тора.

**Ф. ВӘГЫЙЗОВА.**

# Халык контроле листогы № 8

## ДОЗОРЧЫЛАР УКУЫ

Күптән түгел халык контроленың район комитеты группа председательләренең укуын үткәрде.

Семинарда «Халык контроле группалары һәм постларында отчетлар һәм сайлаулар йомгаклары, 1990 елга дозорчыларның бурычлары турында» доклад белән халык контроленың район комитеты председателе Ф. М. Галимов чыкты. Ул чыгышында үзгәртеп коруларның бүгенге шартларында дозорчыларның бурычларына аеруча басым ясады.

Киңәшмәдә сүз алган халык депутатларының район Советы башкарма комитеты секретаре Т. А. Назарова халык депутатларының җирле Советлары даими комиссияләренең бурычлары һәм аларның халык контроле группалары белән бергә эшләве турында сөйләде.

Район халык контроле комитеты инспекторы П. И. Федоров халык контроле группалары эшен планлаштыру һәм өстенлекле юнәлешләрдә дозорчылар тикшерүләрен үткәрү мәсьәләләренә тукталды.

Аннан соң сүз алган халык контроле район комитетының штаттан тыш сәүдә бүлеге мөдире Ф.Х. Хәсәншина кибетләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү сфералары эшен тикшерүне оештыру юлларына тукталды. Сөт-май заводының лаборатория мөдире Н. В. Кудряшова дәүләткә тапшырыла торган сөтнең сыйфатын тикшерүне оештыру мәсьәләләре турында сөйләде. АПК работниклары профсоюз райкомы секретаре Р. Н. Садыйков эшче контроле комиссияләренең бурычлары һәм аларның халык контроле группалары белән элемтәдә эшләве мәсьәләләренә тукталды.

Киңәшмә барышында дозорчылар халык контроле группалары һәм постлары эшчәнлеген оештыру буенча проблемалы ситуацияләр буенча заданиеләр алдылар һәм андый очракта ничек эш итәргә кирәклеге турында фикер алыштылар.

Киңәшмә барышында чыгыш ясаучылар, анда катнашучылар сорауларына җаваплар да бирелде.

### Халык контроленың район комитетында

## Халык теләгән исәпкә алып

Халык контроленың район комитеты «Халыкка хезмәт күрсәтү белән бәйле предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең эш режимындагы җитди кимчелекләр турында» СССР Министрлар Советының карарын үтәүнең барышын тикшерде. Тикшерү барышында бу сферадагы кайбер оешмаларның эш режимын тәртипкә салу буенча тиешле чаралар күрелмәве ачыкланды.

Автопредприятиенең (директоры И. М. Вәлиев) шәһәр эчендәге маршрутларда пассажирлар йөртү режимы халыкта ризасызлык тудыра. Беренче автобус шикәр заводы поселогыннан 6 сәгать 10 минутта китә. Барлык автобуслар да эш көнен шул маршрут белән башлыйлар. Һәм еш кына күрсәтелгән вакыттан соңга калып йөриләр. Бу шәһәр үзәгендә һәм Кормыш поселогында яшәүчеләргә җайсызлыклар китереп чыгара. Линиядә автобуслар аз, шул сәбәпле алар хәрәкәте арасындагы интерваллар зур. Иртән 7—9 сәгатьләрдә һәм кичен 16—18 сәгатьләрдә эшкә барганда һәм аннан кайтканда халыкка кыенлыклар китереп . чыгара.

Автобус йөртүчеләрнең эшенә контрольлек йомшак, шул сәбәпле график һәм хәрәкәт интерваллары бозыла.

Нурлатта, шулай ук күпчелек торак пунктларда кибетләр, ателье, элемтә бүлекләре һәм башка конторалар электәгечә хезмәт ияләре производствода вакытта гына эшлиләр. Шуңа күрә гражданнар шәхси мәсьәләләрне хәл итү өчен эштән сорап китәргә, администрация рөхсәте белән ял алырга яисә билгеләнгән хезмәт режимын бозарга мәҗбүр булалар.

Сәүдә хезмәте күрсәтүдә дә (райпо председателе М. М. Сафин) җитди кимчелекләр яшәп килә әле. Сатып алучыларга хезмәт күрсәтү культурасы түбән, сәүдә кагыйдәләрен һәм кибетләрнең эш режимын бозу очраклары бар. Мисал өчен 12 январьда рейд бригадасы членнарына Чулпан кибетендә вакытыннан элек аракы сату факты билгеле булды. Кибетнең ярдәмче биналарын тикшерү барышында биредә 120 шешәдән артык аракы һәм коньяк, башка төр кондитер әйберләре яшереп куелганлыгы ачыкланды.

Кибетләрнең эш режимын тикшерү барышында райпо идарәсенең аларны вакытында ачу, ябу мәсьәләләсендә йомшак контрольлек итүләре ачыкланды. Мәсәлән, 10 январьда 10 нчы кибет 17 сәгать 40 минутта, 12 январьда 22 нчесе 17 сәгать 45 минутта ябылды.

Көнкүреш хезмәте күрсәтү производство идарәсе (начальнигы Р. С. Хәмидуллин) эшендә дә җитди кимчелекләр яшәп килә. Биредә күпчелек цехлар һәм участоклар иртәнге 8 сәгатьтән 17 сәгатькәчә эшли, якшәмбе көннәрендә ял итә. Сәгать ремонтлау, көнкүреш техникасын һәм суыткычлар, аяк киемнәре, радиотелевизион аппаратура ремонтлау мастерскойлары, прокат цехы һәм башкалар шулай эшли.

Элемтә предприятиеләрендә дә халыкка хезмәт күрсәтүдә кимчелекләр бетерелмәгән әле. 12 январьда сатып алучылар сигналы буенча «Союзпечать»ның беренче киоскысы (киоскеры А. П. Комарова) тикшерелде. Анда 100 сумнан артыклык «Родопи» һәм «Астра» сигаретлары яшереп куелганлыгы ачыкланды.

Комитет утырышында мәсьәләне тикшерү барышында әлеге тармаклар эшендә яшәп килгән башка кимчелекләр дә күрсәтелде. Комитет бу төр предприятиеләр җитәкчеләренә үз карамакларындагы цехлар, подразделениеләр участоклары эш режимын халыкка уңайлы вакытларга күчерү мәсьәләсен яңадан карауны йөкләде.

## Җәза урынына... бүләк

Эчүчелеккә каршы көрәш буенча партия һәм хөкүмәтебезнең мәгълүм карарларыннан соң һәр урында дисциплинаны ныгыту, исереклекне кисәтү буенча чаралар күрелә башлады. Әмма соңгы вакытларда бу мөһим мәсьәләгә игътибар кими төште. «Норлатнефть» НГДУсының юл участогында әлеге мәсьәләнең куелышы белән танышу моны ачык күрсәтә.

Юл участогында (начальнигы В. И. Мусин) администрация һәм җәмәгать комиссияләре эчүчеләр, хезмәт һәм производство дисциплинасын бозучыларга каршы көрәш җитәрлек актив алып барылмый әле . бүген. 1988 елда НГДУ приказы нигезендә 6, былтыр 5 кеше җәзага тартылган. Прогулчыларның ялларын киметелә, айлык, еллык премияне кисү, кварталга чиратны артка күчерү кулланыла дөрес, тик болар аз тәэсир итә.

Участокта тәртип бозулар шактый еш кабатланса да, эчүчелеккә каршы комиссия 1988 елда 3 тапкыр утырыш үткәргән, анда 7 кешенең тәртибе тикшерелгән һәм җәза кулланылган булса, үткән ел ул бер эшче— К. Лобачевның тәртибен генә караган. Өченче ел 5 цехком утырышында 14, былтыр ике утырышта 4 эшченең тәртибе каралган. Былтыр иптәшләр судының бер утырышы да үткәрелмәгән.

Бу—участокта дисциплина ныгый бара дигән сүз түгел әле. Бу чаралар гадәттә сирәк кулланыла, күпләр җәзадан читтә кала. Шуңа күрә чынбарлыкта тәртип бозучылар кимүгә түгел, үсешкә таба бара. Былтыр коллективның 2 вәкиле җинаять җаваплылыгына тартылган, 15се исерек килеш автотранспорт белән идарә иткән өчен тоткарланды. Шунысы да бар, бу аннан алдагы ел белән чагыштырганда артыграк. Былтыр участокның 26 эшчесе вак хулиганлык, җәмәгать урыннарында исерек күренгән өчен төрле җәзага тартылды. В. Хисмәтуллин, Р. Галиев, В. Антонов милиция тарафыннан 2—3 тапкыр тоткарландылар. И. Вәлиәхмәтов исә исерек хәлдә 4 тапкыр РОВДга китерелде.

Моның сәбәпләре участок җитәкчеләренең инженер-техник работникларның рейска чыгу алдыннан һәм гаражга кайткач, шоферларның торышына тиешле контрольлек булдырмавы аркасында килеп чыга. Кайбер шоферлар рейс алдыннан медицина тикшерүе үтмиләр. Мәсәлән, тикшерү көнендә 17 шоферның 4 се шундый тикшерү узмаган булып чыкты.

Участокта дисциплинаның аксауга инженер-техник һәм бухгалтерия работникларының мондый күренешләрне яшереп калырга омтылулары да китерә. Мисалга участок слесаре И. Әбделвәлиев исерек килеш вак хулиганлык эшләгән өчен былтыр 5 тәүлеккә—30 январьдан 3 февральгәчә кулга алына. Бу вакытта ул табель буенча эштә санала һәм аңа 18 сум 96 тиен хезмәт хакы языла.

Бульдозер машинисты Р. Галиев командировкада чагында исерек хәлдә вак хулиганлык эшләгән өчен 3 августта 5 тәүлеккә кулга алына һәм участокта җәза урынына... материаль кызыксындыру ала, ягъни хезмәт хакы һәм хәтта 10 сум 49 тиен күләмендә командировка акчасы да ала.

Грейдер машинисты Р. Кәлимуллин да шундый маҗараларга тап була: ноябрь башында 7 тәүлек төрмәдә утырып чыккач, участокка килсә хәйран кала —ул «ял» иткән 2, 4 ноябрьгә эш көне һәм 18 сум артык хезмәт хакы язып куйганнар.

Хопр-дозатор эшчесе Е. Филиппов сәрхүш баштан явыз ният белән хулиганлык кылганы өчен халык суды тарафыннан 10 тәүлеккә хөкем ителә. Документлар буенча тикшереп карасаң, ул «отгул» алган булып күренә.

Элекке шофер И. Вәлиәхмәтовның маҗаралары үзе бер тарих язарлык. Шофер чагында 30 январьда һәм 22 февральдә исерек килеш милициягә эләгә, 30 ар сум штрафка тартыла, моның өчен цехком утырышында карыйлар каравын, әмма тәэсире булмый. Ноябрь аенда исерек килеш транспорт белән идарә иткән хәлдә эләгә һәм 3 елга бу хокукыннан мәхрүм ителә. Инде транспортсыз гына хулиганлык итеп йөри, 17 ноябрьдә 5 тәүлеккә хөкем ителә.

Балык башыннан чери, диләр бит. Җитәкчеләр арасында гади эшчеләр өчен «үрнәк күрсәтүчеләр» дә табыла. 28 сентябрьдә механик Р. Сөбханкулов үзе дә исерек килеш ГАИ работниклары тарафыннан туктатыла һәм 200 сум күләмендә штраф түли.

Тәртип бозучыларны шулай материаль кызыксындыргач, өлкән иптәшләре үрнәк күрсәткәч, участок эшчеләренә ни үпкә?!...

**П. ФЕДОРОВ,**
халык контроленың район комитеты инспекторы.



1964 елдан КПСС члены Геннадий Александрович Голубевның җәмәгать поручениеләре күп. Бюро члены, халык контроле группасы, хезмәт буенча бәхәс комиссиясе члены вазифаларын үз хезмәте белән бәйләп алып баруы аңа бик үк җиңел түгелдер. Әмма котельнялар слесаре моңа күнеккән инде. Геннадий Александрович 25 ел инде сөт-май заводы котельнясында слесарь булып эшли. Элек ул Норлат-Октябрь сөт-май комбинатының Аксубайдагы филиалында эшләгән, ә 1987 елдан бирле Норлат шәһәрендә яши һәм үзенең өйрәнгән хезмәтен биредә дәвам иттерә.

Табигате буенча сабыр холыклы, намуслы эшче тапшырылган эшенә үтә җаваплылык белән карый. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Чөнки сөт-май заводында бер генә эшне дә чиратка куярга ярамый. Ул аларның һәркайсы үз хезмәтенә бәйле булуын яхшы аңлый һәм шуңа да эштә сүлпәнлек күрсәткәнне сөйми. Ул башкарган һәр эш сыйфатлы булуы белән аерылып тора.

Рәсемдә: сөт-май заводы слесаре Г. А. Голубев.

## Группаларда отчет-сайлаулар

Отчет һәм сайлаулар барышында урыннарда халык контроленың 73 баш, 15 цех группасы һәм 31 пост төзелде. Дозорчылар итеп барлыгы 1067 кеше сайланды.

x x x

СССР халык контроленың тәкъдимен исәпкә алып, колхоз-совхозлар һәм авыл Советлары территориясендә бердәм территориаль -производство группалары оешты. Районда отчет-сайлаулар барышында шундый 29 группа оештырылды.

x x x

Отчет-сайлау барышында 21 группа председателе альтернатив кандидатлар арасыннан сайланды.

